МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.02.2023 Казан ш № 109

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 5 июлендәге 514 номерлы боерыгы белән расланган Бөек Ватан сугышы ветераны катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 5 июлендәге 514 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 №309, 22.06.2015 №425, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №350, 07.05.2018 №347, 19.09.2018 №892, 09.01.2019 №8, 13.05.2019 №362, 14.11.2019 №1022, 10.02.2020 №84, 14.07.2020 №512, 02.10.2020 №690, 24.02.2021 №102, 23.11.2021 №864, 14.11.2022 №1001 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Бөек Ватан сугышы ветераны катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.02.2023 ел, №109 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 5 июлендәге 514 номерлы боерыгы белән расланган Бөек Ватан сугышы ветераны  катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектәге 1.2.2 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.5 пунктында «, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең эрактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга.